МУНИЦИПАЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«УПРАВЛЕНИЕ ДОШКОЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ»
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА НИЖНЕКАМСКОГО РАЙОНА И
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Конспект занятия по обучению татарскому языку в старшей группе

Тема: “Тылсымлы кыш.”

Подготовила:
воспитатель по обучению татарскому языку
Ахметшина Рушания Галимзяновна

город Нижнекамск
2012 год

Тема: Тылсымлы кыш.

Программа эчтәлеге:
1.Балаларның кыш һәм кышкы уеннар турындагы белемнәрен гомумиләштерү.
2.Схема кулланып хикәя төзү өстендә эшне дәвам итү. Хәтер һәм фикерләү сәләтен үстерү.
3.Кышкы табигатькә карата соклану хисләре уяту.
4.Халык авыз иҗатына кызыксыну тәрбияләү.
Сүзлек: кыш, кар, кар бөртеге, салкын, чана, чаңгы, тимераяк.
Җиһазлау:Магнитлы такта, кар бөртекләре, уенчык фил, кояш һәм кояш нурлары, рәсем-схема, алдан шәм белән рәсем ясалган альбом битләре, буяулар.
Алдан эшләнгән эшләр: Кышкы табигатьне күзәтү, рәсемнәр карау, аларның эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру, шигырьләр, сынамышлар өйрәнү, табышмаклар әйтү.
Шөгыль барышы:
Оештыру моменты
Шигырь юллары белән исәнләшү.
Хәерле иртә, агачлар,
Хәерле иртә, кошлар!
Хәерле иртә, табигать,
Хәерле иртә, дуслар!
Тәрбияче: Балалар, әйдәгез, бармак уены уйнап алабыз.

Баш бармагым – кыш була,
Кар-бураннары туза.
Имән бармак – яз килә,
Карлары эреп бетә.
Урта бармак - җәй җитә
Җиләк кызарып пешә.
Атсыз бармак – көз икән,
Сары яфраклар сипкән.
Чәнти бармак ни икән?
Кыш, яз, җәй, көз бит үткән.

Тәрбияче: Ә хәзер урамда елның кайсы вакыты?
Балалар: Кыш.
Тәрбияче:Балалар, бүген безгә фил кунакка килгән. Ул бик туңган, чөнки җылы якта яши. Ә анда кыш бөтенләй булмый. Филнең бик тә кыш турында беләсе килә, ди. Ул үзе белән бер серле тартма да алып килгән, әммә ул тартманы ачып булмый, ул филнең теләген үтәсәк кенә ачыла. Әйдәгез, аңа кыш турында сөйләп бирик. Сез ризамы?
Балалар: Әйе!
Тәрбияче:Әйдәгез әле кыш турында өйрәнгән шигырьләрне искә төшерик.
- “Йомшак кар” Ә. Бикчәнтәева.
- “Кар яуган” З. Нури.

Тәрбияче: Балалар, хәзер бер уен уйнап алабыз, уенның исеме “Мин башлыйм, син дәвам ит” дип атала.
Тәрбияче кыш турындагы сынамышларның башын, балалар ахырын әйтә. Һәрбер дөрес җавап саен магнит тактадагы кояшка нурлар куела бара.

- Эт карда аунаса, көн аяз булыр.
- Бүген мәче тырнаша, буран булыр.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
- Сентяберь аяз, кыш салкын.
- Кышын кар күп булса, җәй яңгырлы була.
- Әгәр кар вак, сирәк төшсә, озак суык булыр.
- Ябалак кар яуса, аннан соң җылы булыр.

Тәрбияче: Сез дөрес җаваплар әйткәч, кояш үзенең нурларын сипте, филгә җылы булып китте. Ул сезгә рәхмәт әйтә.

Балалар, бер табышмак әйтәм, игътибар белән генә тыңлагыз һәм җавапны әйтегез.

Ак кын, вак кына
Ак мамык сымак кына.
Югала юк, юк була
Учта тотсаң чак кына.
(кар бөртеге)

Тәрбияче балаларга кар бөртекләре тарата:

- Һәрбер бала кар бөртегенең билгеләрен әйтеп чыга.....(ак, салкын, йомшак, ялтырый, һ.б.)
- Сүзләрне берлек һәм күплек санда әйтәләр (кар – карлар, кар бөртеге – кар бөртекләре)

Ял минуты.
“Кар бөртекләре уены”

Тәрбияче: Әйдәгез, балалар, хәзер урыннарыгызга утырыгыз һәм кыш турында сөйләшүебезне дәвам итәбез.
Схема буенча хикәя төзеп сөйләү.
Кыш җитте. Кыш көне кояш җылытмый. Ак, матур кар ява. Җир өстендә, агачларда, түбәләрдә кар ята. Кыш көне агачларның яфраклары булмый, алар йоклыйлар. Кешеләр җылы итеп киенә, чөнки урамда салкын. Кыш көне балалар чанада, чаңгыда, тимераякта шуалар. Без кышны яратабыз.
Тәрбияче: Булдырдыгыз, балалар! Без сезнең белән кыш турында белгәннәребезне искә төшердек. Кыш көне табигать үзенчә матур, бөтен дөнья аклыкка күмелгән. Аның матурлыгына сокланып шагыйрьләр - шигырьләр, компазиторлар - көйләр язганнар. Хәзер мин сезгә кыш турында язылган бер матур җыр тыңларга тәкъдим итәм.
Җыр тыңлау.
«Кышкы җир» Г. Гәрәева сузләре һәм көе.
Тәрбияче:Балалар без кунагыбызга кыш турында бик күп сөйләдек, менә хәзер фил алып килгән серле тартма ачылды, аның эчендә менә нинди альбом битләре бар. Алар да серле икән, альбом битләрен зәңгәр буяаулар белән

буярга кирәк. Әйдәгез хәзер өстәлләр артына күчеп утырабыз һәм эшкә керешәбез.
Һәрбер баланың кәгазендә берәр кыргый җәнлек рәсеме килеп чыга, һәм бала аның исемен, кыш көне ничек яшәве турында әйтә.
(Бу- куян. Куян кышын ак тун кия.
Бу – аю. Аю кышын йоклый. һ.б.)
Йомгаклау өлеше.

Файдаланылган әдәбият һәм интернет ресурслары:
1.«Гөлбакча» (Хрестоматия для татарских детских садов). Казань: Татарское кн. изд-во, 1990 (255 с., на татарском языке)
2.http://halik-ishati.ucoz.ru/index/tatar_khalyk_synamyshlary/0-6